**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 2 июлендәге 2817 номерлы карары**

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 25 маендагы 2128 номерлы карары белән расланган 2016-2025 елларга Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы нигезендә (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге 5316 нчы номерлы, 2017 елның 4 апрелендәге 976 нчы номерлы, 2018 елның 5 февралендәге 491 нче номерлы, 2018 елның 26 февралендәге 749 нчы номерлы, 2018 елның 8 августындагы 4328 нче номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 5933 нче номерлы, 2019 елның 13 маендагы 1705 нче номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 2711 нче номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 3986 нчы номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 3983 нче номерлы, 2022 елның 27 гыйнварындагы 270 нче номерлы, 2023 елның 25 июлендәге 2088 нче номерлы, 2023 елның 19 декабрендәге 4172 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) **карар бирәм**:

1. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында түбәндәге номинацияләрдә шәһәр конкурсы игълан итәргә:

- «Балалар һәм яшүсмерләр арасында террорчылыкны, экстремизмны һәм ксенофобияне профилактикалау буенча иң яхшы проект»;
- «Яшьләрне һәм гражданнарны деструктив һәм криминаль оешмаларга җәлеп итүгә каршы тору буенча иң яхшы проект».

2. Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турындагы нигезләмәне (1 номерлы кушымта) расларга

3. Конкурс комиссиясе составын расларга (2 номерлы кушымта).

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 18 августындагы 2341 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru) һәм аны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга».

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 2 июлендәге 2817 номерлы карарына 1 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында түбәндәге номинацияләрдә шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) уздыру максатларын, бурычларын һәм тәртибен билгели:

- «Балалар һәм яшүсмерләр арасында террорчылыкны, экстремизмны һәм ксенофобияне профилактикалау буенча иң яхшы проект»;
- «Яшьләрне һәм гражданнарны деструктив һәм криминаль оешмаларга җәлеп итүгә каршы тору буенча иң яхшы проект».

1.2. Конкурсны оештыручы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалата бүләкне бирү буенча вәкаләтле орган булып Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты тора.

Конкурсның эшче органы булып составы әлеге карар белән раслана торган конкурс комиссиясе (алга таба – Комиссия) тора. Конкурсны оештыру өлешендә турыдан-туры эш башкаруны Комиссия сәркатибе гамәлгә ашыра.

1.3. Конкурста Казан шәһәре территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыручы гражданнар катнаша.

1.4. Комиссия тарафыннан конкурста җиңүчеләр дип танылган гражданнарга Казан шәһәре бюджеты акчалары хисабыннан акчалата бүләк тапшырыла.

1.5. Акчалата бүләкләү 2016-2025 елларга Казанда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыруга Казан шәһәре бюджетында каралган 2024 елга бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

## II. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

Конкурсның максатлары – гражданнар бердәмлеген тәэмин итү эшендә гражданнарның ролен күтәрү һәм Казан шәһәрендә террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлдерелгән социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга булышлык итү.

Конкурсның бурычлары – толерантлыкны, милләтара татулыкны үстерү, яшьләр арасында экстремизм һәм террорчылык таралуны кисәтү, шулай ук детруктив психологик йогынтыга дучар булган балаларны һәм яшүсмерләрне кабаттан социальләштерү буенча иң яхшы проектларны ачыклау.

## III. Конкурсны үткәрү, нәтиҗәләр ясау тәртибе, конкурста җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү

3.1. Конкурсны уздыру турында мәгълүмат һәм нигезләмә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) «Террорчылыкка каршы комиссия» өстәмә битендә, агымдагы елда конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә урнаштырыла. Башка затлар тарафыннан авторлыкка дәгъвалык итүне булдырмау максатыннан авторлар ризалыгы белән әлеге биттә тапшырылуга бәйле рәвештә Комиссиягә тапшырылган проектлар турында мәгълүмат урнаштырыла.

3.2. Казан шәһәре территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданнарына конкурста катнашу рөхсәт ителә.

3.3. Конкурста катнашырга теләк белдергән гражданнар агымдагы елның 15 сентябреннән дә соңга калмыйча Комиссиягә конкурста катнашуга гариза тапшыра. Комиссия тапшырылган материалларны агымдагы елның 1 октябренә кадәр карап тикшерә һәм конкурста җиңүчеләр турында карар кабул итә.

3.4. Комиссия гаризаларны һәм аларга кушып бирелгән документларны әлеге нигезләмәнең 2 номерлы кушымтасында бирелгән критерийлар нигезендә бәяли.

3.5. Җиңүчеләрне билгеләгәндә шулай ук түбәндәгеләр исәпкә алынырга мөмкин:

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендәге бурычларны исәпкә алып, гражданнарның эшчәнлек юнәлешләрендәге актуальлек, яңалык, максатчанлык;

- элек хөкем ителгәннәрне һәм аларның гаилә әгъзаларын, шул исәптән экстремизм һәм террорчылык юнәлешендәге статьялар буенча, кабаттан

социальләштерү һәм тормышка җайлаштыру эшчәнлеге;

- хакимият органнары, яшьләр сәясәте учреждениеләре, мәгариф, мәдәният һәм иҗтимагый оешмалар арасында ведомствоара хезмәттәшлек ресурсларын җәлеп итү;

- практик нәтиҗә (продукт) булу һәм террорчылык, экстремизм идеологияләренә бирелгән затлар белән алга таба профилактика эше алып баруда, шул исәптән яшьләр мохитендә аны куллана алу мөмкинлеге;

- проектның ахыргы продуктын гамәлгә ашыруда (гамәли эшчәнлектә файдалануда) катнашкан кулланучы бәяләмәсе (конкурс үткәрүне, бүләкләүне һәм вәкаләтле орган тарафыннан салым агенты бурычларын үтәүне башкару максатыннан 3 номерлы кушымтадагы форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык таләп ителә).

3.6. Конкурста катнашу өчен гражданнар Комиссия сәркатибенә (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3 йорт, 637 бүлмә, тел. 299-17-59) кәгазьдә түбәндәге документларны тапшыра:

- әлеге нигезләмәгә 1 номерлы кушымтада бирелгән форма буенча гариза;

- террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә проект;

- проектның ахыргы продуктын гамәлгә ашыруда (гамәли эшчәнлектә файдалануда) катнашкан кулланучының әлеге нигезләмәгә 4 номерлы кушымтадагы форма буенча кәгазьдә бәяләмә;

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

3.7. Комиссия сәркатибе эш көне дәвамында Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының эш башкару идарәсенә керүче документларны теркәүне тәэмин итә.

3.8. Гражданнар конкурска бер социаль әһәмияткә ия проектны үз эченә алган бер гариза тапшыра.

3.9. Әлеге нигезләмә белән билгеләнгән документларны тапшырган гражданнарга конкурста катнашу рөхсәт ителә. Гражданнарны конкурста катнаштыру түбәндәгеләргә нигезләнеп кире кагылырга мөмкин:

а) документларны тапшырмау яисә документларны тулы күләмдә тапшырмау;

б) документларның әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

в) документларны гаризалар бирү срогы тәмамланганнан соң тапшыру.

3.10. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү Комиссия утырышында Комиссия әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән башкарыла.

Комиссия утырышы, әгәр утырышта кимендә 2/3 Комиссия әгъзасы

катнашса, хокуклы санала.

Тавышлар тигез булган очракта Комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч тавыш булып тора. Комиссия утырышында рәис булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара. Гаризалары һәр номинациядә иң күп балл җыйган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре булалар.

Конкурста катнашуга бер гариза алынган очракта, проект конкурс таләпләренә һәм критерийларына туры килсә, гражданин җиңүче санала.

Конкурста җиңүчеләрне билгеләү буенча Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия утырышы узган көннән алып бер эш көне дәвамында рәсмиләштерелә, Комиссия рәисе яки утырышта Комиссия рәисе функцияләрен башкаручы урынбасар һәм Комиссия сәркатибе тарафыннан имзалана.

3.11. Әлеге нигезләмә буенча беркетмә имзаланган көннән алып бер ай эчендә бүлеп бирелгән финанслау кысаларында Комиссия беркетмәсе нигезендә җиңүчеләргә акчалата бүләк тапшырыла:

- 100 мең сум – «Балалар һәм яшүсмерләр арасында террорчылыкны, экстремизмны һәм ксенофобияне профилактикалау буенча иң яхшы проект» номинациясендә җиңүчегә;

- 80 мең сум – «Яшьләрне һәм гражданнарны деструктив һәм криминаль оешмаларга җәлеп итүгә каршы тору буенча иң яхшы проект» номинациясендә җиңүчегә.

3.12. Конкурс нәтиҗәләре һәм җиңүчеләр турында мәгълүмат Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында, «Террорчылыкка каршы комиссия» өстәмә битендә, конкурста җиңүчеләр исемлеген раслаган көннән соң өч көн эчендә урнаштырыла.

3.13. Конкурста җиңүчеләргә нәтиҗәләрне игълан иткән көннән алып өч эш көне эчендә Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе исеменә, әлеге нигезләмәнең 5 номерлы кушымтасындагы форма буенча банк реквизитларын күрсәтеп, акчалата бүләк күчерү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Шул ук вакытта гаризага паспорт күчермәсен, салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) күчермәсен, СНИЛС күчермәсен беркетергә кирәк.

3.14. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантаналы шартларда үткәрелә.

Террорчылыкны һәм
экстремизмны профилактикалау
өлкәсендә социаль әһәмиятле
проектларны гамәлгә ашыруда
катнашучы гражданнар
арасында шәһәр конкурсы
турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә
социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы
гражданнар арасында шәһәр конкурсында катнашуга
**гариза**

1. Дәгъва кылучының фамилиясе, исеме, атасының исеме: ________________________________
2. Адрес: ______________________________________________, телефон ____________________,
e-mail: ______________________________________________________
3. Проект исеме: _____________________________________________________________________
Номинация исеме: ___________________________________________________________________
Проект авторы: ______________________________________________________________________
Элемтә өчен мәгълүмат: ______________________________________________________________
4. Проектка кыскача аннотация
Проблеманың тасвирламасы:___________________________________________________________
____________________________________________________________________________________
Проектның максаты һәм бурычлары: ___________________________________________________
Үткәрелгән чаралар планы: ___________________________________________________________
Алынган нәтиҗәләр: __________________________________________________________________
Проект зарурлыгын нигезләү: _________________________________________________________
5. Гаризага беркетелә торган материаллар: ______________________________________________

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә каршы түгеллегемне белдерәм.

Гражданинның имзасы _______________________ / ______________________________/
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Дата: ____________________

Террорчылыкны һәм экстремизмны
профилактикалау өлкәсендә
социаль әһәмиятле проектларны
гамәлгә ашыруда катнашучы
гражданнар арасында шәһәр
конкурсы турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсында катнашучыларны бәяләү критерийлары**

| № т/б | Гаризаларны бәяләү критерийлары | Бәяләү (балл) |
|---|---|---|
| 1 | Проектның конкурс тематикасына туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 2 | Проект буенча хәл ителергә тиешле бурычларның актуальлеге | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 3 | Проект чараларының логикага нигезләнгәнлеге, үзара бәйләнеше һәм эзлеклелеге | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 4 | Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре булу, аларның проект бурычларына туры килүе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 5 | Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә планлаштырылган чараларның ярашлы булуы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 6 | Проект чараларының максатчан төркемне яхшыртуга йогынты ясау дәрәҗәсе | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан 0 дән 10 га кадәр билгеләнә |
| 7 | Төзелгән сайт булу | Юк – 0, әйе – 1 |

Террорчылыкны һәм
экстремизмны профилактикалау
өлкәсендә социаль әһәмиятле
проектларны гамәлгә ашыруда
катнашучы гражданнар
арасында шәһәр конкурсы
турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә**
**РИЗАЛЫК**

Мин, ________________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ___________________________________________,

паспорт: сериясе _____ номеры ____________ «____» _______________ тапшырылган
(тапшыру датасы)

_____________________________________________________________________________,
(документны тапшырган орган атамасы)

_____________________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ___________________________________________,

паспорт: сериясе _____ номеры ____________ «____» _______________ тапшырылган
(тапшыру датасы)

_____________________________________________________________________________,
(документны тапшырган орган атамасы)

_____________________________________________________________________________,
[ышаныч кәгазе яки әлеге вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган башка документ реквизитлары
(шәхси мәгълүматлар субъекты вәкиленнән ризалык алганда)]

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә, конкурс уздыру һәм акчалата бүләк алу максатыннан, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә операторга – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенә шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән аларны җыюга, язуга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), алуга, файдалануга, тапшыруга (таратуга, тәкъдим итүгә, файдалану өчен мөмкинлек бирүгә), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, чикләүгә, юкка чыгаруга, шәхси мәгълүматларны бетерүгә, аерым алганда (алга таба кирәклесен сызу зарур)

автоматлаштырып, шулай ук автоматлаштыру чаралары кулланылмыйча эшкәртү өчен ризалыгымны бирәм:

1) фамилия, исем һәм атасының исеме, яшәү урыны (теркәлү һәм факттагы) буенча адрес, электрон почта адресы һәм телефон номеры турында мәгълүматларны кертеп, анкета белешмәләрен;

2) сериясен, номерын, бирү датасын, документны биргән органның атамасын кертеп, паспорт яки шәхесне һәм гражданлыкны таныклый торган башка документ турында белешмәләрне;

3) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры турында мәгълүматларны;

4) салым органында исәпкә кую турында мәгълүматларны;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында мәгълүматларны;

6) бюджеттан тыш фондларга иминият взнослары, пенялар, штрафлар буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматларны;

7) кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетлары турында мәгълүматларны.

8) СНИЛС;

9) рәсми теркәлү урыны турында белешмәләр.

Шәхси мәгълүматларымны өченче як аша гына алып булган очракта, шәхси мәгълүматларымны алуның максатларын, мөмкин булган чыганакларын һәм ысулларын күрсәтеп, миңа бу хакта алдан хәбәр ителергә һәм шулай ук моның өчен ризалык алынырга тиеш.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Ризалык аны имзалаган көннән гамәлгә керә һәм, шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатына ирешкән яки аны язмача кайтарып алган билгесез вакытка кадәр гамәлдә була.

______________________________________________________________________

(имза, фамилия һәм инициаллар)

Ризалык бирү вакыты: «____» ____________ 20___ г.

Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы граждannар арасында шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

**Проектка бәяләмә**

Проектны кулланучының исеме, фамилиясе, атасының исеме:

Проектның темасы:

| | |
|---|---|
| Проектның авторы: | |
| Юнәлеш: | |

**Проектның тәкъдим ителә торган таләпләргә туры килүен бәяләү**

| Туры килү күрсәткечләре | 1 балл | 2 балл | 3 балл | 4 балл | 5 балл |
|---|---|---|---|---|---|
| Проект эчтәлегенең бирелгән критерийларга туры килүе | | | | | |
| Проектның белдерелгән темасын тасвирлауның тулылыгы, тирәнлеге һәм нигезлелеге | | | | | |
| Проектның оригинальлеге һәм актуальлеге дәрәҗәсе | | | | | |
| Мәгълүматны эзләүне, тәнкыйть анализын гамәлгә ашыра белү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен системалы алым куллана белү | | | | | |
| Проектны тасвирлауның профессиональ грамоталылыгы | | | | | |
| Проектта бирелгән иллюстратив фото һәм видеоматериалның сыйфаты | | | | | |
| Проект материалларын гамәли (гамәли-юнәлешле) файдалану | | | | | |
| Проект продуктының сыйфаты һәм проектны башка учреждениеләр базасында файдалану перспективалары | | | | | |

Билгеләп үтелгән уңай сыйфатлар ______________________________________________

Билгеләп үтелгән җитешсезлекләр ______________________________________________

Нәтиҗә ____________________________________________________________

Продуктны кулланучыдан:

Вазифасы ___________________ /фамилиясе, исеме, атасының исеме/

Террорчылыкны һәм
экстремизмны профилактикалау
өлкәсендә социаль әһәмиятле
проектларны гамәлгә ашыруда
катнашучы гражданнар
арасында шәһәр конкурсы
турында нигезләмәгә
5 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль
берәмлеге Башкарма комитеты
Аппараты җитәкчесе**
**______________________________**
кемнән _______________________

______________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
түбәндәге адрес буенча яши:
___________________________,
телефоны____________________

**Гариза**

Конкурста җиңүче буларак миңа тиешле акчалата бүләкне ____________________________________________ банкындагы _____________________
(банк исеме)
хисап номерына түбәндәге реквизитлар буенча күчерүне сорыйм:
____________________________________________________,
банкның идентификация коды (БИК)______________________________,
Банкның тәңгәлләштерү номеры (ИНН)/исәпкә кую сәбәбе коды КПП_________/____________,
Корреспонденция счеты (к/сч.) ______________ бүлекчәдә: ___________________________,
төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН)/предприятиеләрнең һәм оешмаларның гомумроссия классификаторы (ОКПО) ________________________________________________________.
(имза, фамилия, исем, атасының исеме, дата)

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
2 июлендәге 2817 номерлы
карарына
2 номерлы кушымта

**Террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруда катнашучы гражданнар арасында шәһәр конкурсында җиңүчеләрне билгеләү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Б.Р.Алиев | комиссия рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе |
| Г.Р.Сәгыйтова | комиссия рәисе урынбасары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары |
| Л.Н.Замова | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге башлыгы |
| Комиссия әгъзалары: | |
| В.И.Яковлев | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| И.Р.Мөхәммәтшин | Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсе башлыгы |
| И.Н.Сарманов | Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге башлыгы вазифаларын башкаручы |
| Е.С.Ямбаршева | «Казан шәһәр иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе директоры |

_______________